**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» февраль 2019 с. Тюлячи № 68

Район Башкарма комитетының 2018 нче елның 20 нче декабрендә чыккан 850 нче номерлы “Теләче муниципаль районында 2019 елга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2012 нче елның 29 нчы декабрендә чыккан 273нче номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законның 99 нчы статьясы, 2003 елның 6 октябрендә чыккан 131 - ФЗ Федераль законның11 нче пункт 15 нче статьясының 1 өлешендә “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” гы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 нче елның 30 нчы декабрендә чыккан 1096 нчы номерлы “Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эшчәнлеген норматив финанслау турында» гы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Район Башкарма комитетының 2018 нче елның 20 нче декабрендә чыккан 850 нче номерлы “Теләче муниципаль районында 2019 елга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» гы карарының 1 пунктына 1.3 пунктчасын өстәмә итеп түбәндәге эчтәлектә кертергә:

«1.3.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләү керткәндә аерымзатлар өчен 2019 нчы елга ташламалар исемлеге».

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетның
«11» 02 2019 68 санлы
карарына кушымта

Татарстан РеспубликасыТеләче муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караганһәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләү керткәндә аерым затлар өчен 2019 нчы елга ташламалар исемлеге

Теләче муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан түләү алынмый:

- инвалид балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган өчен;
- өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган ата-аналардан мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен 50 процентка киметергә:
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче, ике бала тәрбияләүче, әти-әниләренең берсе 1 нче төркем инвалид булган гаиләдән;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче һәм җан башына уртача кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган,әти-әниләренең берсе1 төркем инвалид булган гаиләдән.

Муниципаль белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен түләүгә ташлама ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы һәм гаиләнең ташламага хокукы булуны раслаучы документлар нигезендә бирелә.

Гаиләнең берничә ташламага хокукы булганда ата аналар (законлы вәкилләр) сайлау буенча бер генә ташламадан файдалана.

2. Әлеге карар гамәлдәге кануннар нигезендә уз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кулланыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х.Хәмидуллин